ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

Казань ш.

14.06.2019 № 69

2019 елда X «Тамырларыбызга сәяхет» республикакүләм бәйгесен үткәрү турында

21.07.2014 дан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 522-нче номерлы ««Татарстан Республикасында 2014-2022 елларга туристлык һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» карар нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасында эчке туристлыкны һәм керем туристлыгын үстерү, яшьләрне инновацион туристлык проектларын тормышка ашыру эшенә җәлеп итү, Татарстан Республикасының өстенлекле туристлык узәкләрен үстерү максатыннан боерык бирәм:

1. 2019 елда «Тамырларыбызга сәяхет» республикакүләм бәйгесен үткәрү турындагы Нигезләмәне (алга таба – Бәйге) расларга.
2. Татарстан Республикасы туристлык буенча Дәүләт комитетының 16.04.2018 нән 32-нче номерлы «2018 елда IX «Үткәннәргә сәяхәт» республика бәйгесен үткәрү турында» карары көчен югалткан дип таныргa.
3. Туристлык тармагын үстерү бүлегенә (А.В.Софьина) Бәйгене әзерләү һәм үткәрү буенча эшне оештырырга.
4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны рәис урынбасары Е.А.Барабановага йөкләргә.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасының
туристлык буенча
Дәүләт комитетының
14.06.2019 дан 69 номерлы
боерык буенча расланган

2019 елда X «Тамырларыбызга сәяхәт» республикакүләм
бәйгесен үткәрү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә 2019 елда IX «Тамырларыбызга сәяхәт» республикакүләм бәйгесен (алга таба – Бәйге) үткәрү тәртибен, Бәйгедә катнашучыларга, бәйге проектларына һәм аларны Бәйгегә тәкъдим итүгщ карата таләпләрне, шулай ук Бәйгене үткәрү вакытын билгели.

1.2. Бәйгенең максаты булып яшьләрне Татарстан Республикасның туристлык үзәкләрен үстерү һәм алга этәрү инновацион туристлык проектларын тормышка ашыруга җәлеп итү, яшьләрнең туган як туристлык ресурслары, аның мәдәни һәм экологик ядкарьләре турында хәбәрдарлыкларын арттыру аша аларда патриотлык хисләр тәрбияләү булып тора.

1.3. Бәйгенең төп бурычлары:

Татарстан Республикасы территориясенә туристларны җәлеп итергә булышучы туристлык, якны һәм мәдәниятне өйрәнү юнәлешендәге проектларны булдыру һәм пропагандалау;

Татарстан Республикасында эчке туристлыкны һәм керү туристлыгын үстерү;

талантлы яшьләрне ачыклау һәм аларны туристлык өлкәсенә җәлеп итү.

1.4. Бәйгене оештыручы булып Татарстан Республикасы туристлык буенча Дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тора.

1.5. Бәйгене финанслау Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 21.07.2014 нән 522-нче номерлы карары белән расланган «2014-2022 елларга Татарстан Республикасында туристлык һәм кунакчыллык өлкәләрен үстерү» дәүләт программасы белән каралган акчалар хисабына башкарыла.

2. Бәйгедә катнашу шартлары

2.1. Бәйгедә катнашу түләүсез, ирекле нигездә башкарыла.

2.2. Бәйгедә Татарстан Республикасының югары, махсус урта белем бирү йортлары (уку йортының профиле һәм уку формасы нинди булуына карамастан) студентлары, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, эшләүче яшьләр, шулай

ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан яшьләр иҗтимагый оешма вәкилләре катнаша.

2.3. Бәйгедә катнашуга проетларны тәкъдим итү ничек белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешмалар, шулай ук дәгъвачыларның үзләре тарафыннан башкарыла. Бәйгедә күмәк эшләр катнашуы да рөхсәт ителә.

Бәйгедә катнашу бер яки берничә номинациядә (теләк буенча) кабул ителә.

2.4. Бәйгедә 14 яшьтән алып 25 яшькәчә (25 яшьне кертеп) физик затлар катнаша.

3. Бәйгене оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Бәйге бер этапта 2019 елның 1-нче августыннан башлап 30-нчы ноябренә кадәр үткәрелә.

Бәйгене үткәрү турында мәгълүмат мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) (алга таба – Дәүләт комитетының сайты) бәйге документларын кабул итү башланганырга 15 көннән дә соңрак түгел кала урнаштырыла.

3.2. Бәйге документларын Дәүләт комитетына тапшыру вакыты 2019 елның 1-нче августыннан башлап 1-нче ноябренә кадәр (1-нче ноябренә исәпкә алып).

Бәйге документлары 420015, Татарстан Республикасы, Казан ш., М.Горький ур., 19 йорт (1-нче кабинет) адресы буенча кулга тапшырыла яки почта аша җибәрелә. Документлар белән шулай ук бәйге проекты теркәлгән флеш-мәгълүмат йөртү җайланмасы да җибәрелә.

Бәйге документларының электрон версиясе шулай ук Бәйгене оештыручының электрон адресына – puteshestviekistokam@mail.ru га юнәлтелә.

3.3. Бәйгедә катнашуга эчтәлеге һәм төзелеше әлеге Нигезләмәнең таләпләренә җавап бирүче әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән вакыт аралыгында тапшырылган бәйге документлары кабул ителә. Бәйгегә билгеле бер туристлык юнәлеше, туристлык үзәге, туристлык индустриясе объекты яки, гомумән, Татарстан Республикасының туристлык комплексы белән бәйле, республика туристлык продуктын булдыру, үстерү яки аны камилләштерүгә, Татарстан Республикасына Рәсәй һәм чит ил туристларын җәлеп итүгә юнәлтелгән тәкъдимнәр чагылдырган бәйге проектлары тапшырыла.

3.4. Бәйге киләсе номинацияләр буенча үткәрелә:

1) Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсион маршрут – бүлекләр буенча:

тарихи мирас маршруты;
авыл туристлыгы маршруты;
этнотуристлык маршруты;

актив туристлык һәм ял итү маршруты;

сәнәгать туристлыгы маршруты;

гастрономия туристлыгы маршруты.

2) Иң яхшы видео-экскурсия.

3) Вакыйгалы туристлык өлкәсендә иң яхшы проект.

3.5. Бәйге һәр номинациия буенча яшь ягыннан ике төрле төркем өчен үткәрелә:

14 тән алып 18 яшькәчә катнашучыларның бәйге проектлары;

19 тән алып 25 яшькәчә катнашучыларның бәйге проектлары.

«Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсион маршрут» номинациясе буенча бәйге проекты үз эченә күрсәтү объектларының тасвирламасы белән экскусриянең турыдан-туры маршрутын, маршрутның карта-сызымын, экскурсия контроль текстын һәм «экспкусрия җитәкчесе портфелен» алырга тиеш.

Экскурсия маршруты экскрусия төркеменең иң җайлы бару юлын чагылдырырыга тиеш. Маршрут әлеге экскурсия өчен объектларны караунын иң дөрес эзлеклелегеннән, төркемне урнаштыру өчен мәйданчык булу-булмавыннан чыгып төзелә. Маршрут бурычларының берсе булып экскурсия темасын мөмкин кадәрле тулы ачу тора. Маршрутны төзүгә төп таләпләр ул – объектларны логик эзлелектә күрсәтүне оештыру һәм теманы ачу өчен күрү нигезен тәэмин итү.

Экскурсиянең контроль тексты ул – экскурсантларга тәкъдим ителә торган мәгълүматның фәнни, яңартылган эчтәлектән гыйбарәт технологик документ. Контроль текст нигезендә экскурсия җитәкчесе үзенең үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен чагылдыручы һәм билгеле экскурсантларның мәнфәгатьләренә җавап бирүче индивидуаль текст төзи (чыганак: ГОСТ Р 50681-2010: Туристлык хезмәтләер. Туристслык хезмәтләрен проектлау).

Экскурсия җитәкчесе портфеле – экскурсияне үткәрү барышында кулланыла торган мәгълъмати материаллар (фотографияләр, документ күчермәләре, географик карталар, сызымнар, рәсем күчермәләре) комплектының шартлы исеме. (чыганак: ГОСТ Р 50681-2010: Туристлык хезмәтләер. Туристслык хезмәтләрен проектлау).

«Вакыйгалы туристлык өлкәсендә иң яхшы проект» номинациясенә алда торган максатлар һәм бурычлар, стратегияләр һәм ул максатларга ирешү механизмы, чаралар планы/графигы, планшлаштырылган нәтиҗәләр, үсеш перспективалары билгеләнелгән туристларны җәлеп итү өчен элемент буларак нинди дә булса чараны (мәдәни, спорт, тарихи, этнографик һәм эшлеклелек характердагы) тасвирлау белән бәйле бәйге проекты тәкъдим ителә.

3.6. Бәйгегә киләсе материаллар тапшырыла:

билгеләнгән формадагы сораунамә-газира (әлеге Нигезләмәгә 1, 2-нче номерлы Кушымталар);

киләсе таләпләргә җавап бирүче проект документлары:

басма материаллар: Word форматындагы текст (шрифт зурлыгы - 12, юллар арасындагы ара – бер иңле), текст күләме –30 000 гә кадәр басма билгеләр )буш араларны исәплкә алып);

фотографик материаллар: PDF/JPG форматында (15 фотографиядән дә артык түгел);

CD/DVD дискларда яки флеш-мәгълъмат йөртү җайланмасында саклanган аудио һәм видеоматериаллар.

Басма материаллар кәгазьдә яки электрон формада тапшырыла.

Барлык тәкъдим ителгән докмент текстлары авторның исеме, фамилиясе һәм белем бирү эшчәнлеген алып баручы оешманың исемен күрсәтү белән башланырга тиеш.

Бәйге материаллары рус теленә тәрҗемәләре булган очракта гына теләгән чит телдә (шулай ук татар телендә дә) тапшырылырга мөмкин.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.2 пуктында күрсәтелгән вакыттан соңрак тапшырылган Бәйге документлары каралмый һәм Бәйгедә катнашуга үткәрелми.

3.8. Бәйгегә җибәрелгән барлык материаллар да кире кайтарылмый һәм рецензияләнми.

## 4. Сайлап алу тәртибе

4.1. Кабул ителгән бәйге проектларын бәяләү максаты белән Дәүләт комитеты тарафыннан Бәйге комиссиясе барлыкка китерелә (алга таба - Комиссия).

4.2. Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм җаваплы сәркатибе җитәкчелегендәге республика башкарма хакимияте әгъзалары, Татарстан Республикасы туристлык һәм иҗтимагый оешмалары, фәнни берләшмә вәкилләре арасыннан 12 кешедән торган Комиссиянең шәхси составы Дәүләт комитеты боерыгы нигезендә раслана.

4.3. Комиссиянең эше белән аның рәисе җитәкли. Ул булмаган очракта вазифалар аның урынбасарына йөкләнә. Комиссия үзе артыннан өстәмә экспертлар җәлеп итү хокукын калдыра. Бәйге нәтиҗәләрендә шәхси кызыгы булган затлар Комиссия әгъзалары буларак катнаша алмый.

4.4. Комиссия эше аның утырышы барышында башкарыла. Утырышта аның әгъзаларының гомуми санынннан өчтән ике өлешеннән дә киме булмаган саны катнашкан очракта, андый утыраш хокуклы дип санала. Комиссиянең җаваплы серкатибе тавыш бирү хокукына ия түгел.

4.5. Комиссиянең җаваплы сәркатибе киләсе функцияләрне башкара:

әлеге Нигезләмәнең 3.6-3.8 пунктлары нигезендә билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып материалларны кабул итә һәм аларны терки, шулай ук аларны саклауны оештыра;

Комиссиянең утырышын оештыра, документларны әзерли һәм беркетмә төзи.

4.6. Комиссия карары утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы ярдәмендә кабул ителә һәм рәислек итүче белән җаваплы сәркатип тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар саны бертигез булган очракта рәиснең тавышы хәлиткеч булып санала.

4.7. Бәйгедә катнашучы Бәйге нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта ул Бәйге комиссиясенә апелляциягә бирергә хокуклы.

Апелляция ирекле формада язма рәвештә Комиссия рәисе исеменә төзелә һәм Комиссия беркетмәсе Дәүләт комитеты сайтында бастырылганнан соң 3 эш көне эчендә бирелә һәм Комиссия әгъзаларына юнәлтелә.

Комиссии әгъзалары аппеляцияләр кабул итү вакыты тәгәлләнгәннән соң 4 эш көне эчендә аларны карый һәм бергәләп фикер алыша. Карар күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы ярдәмендә кабул ителә һәм Комиссия әгъзаларының күпчелеге катнашкан очракта легитим дип танылa. Тавышлар исәбе бертигез булган очракта Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч дип санала. Комиссиянең җаваплы сәркатибе Комиссия карары нигезендә беркетмә төзи. Беркетмәдә Комиссиянең һәрбер әгъзасының:

апелляцияне кире кагу һәм бастырылган нәтиҗәләрне көчендә калдыру турында;

апелляцияне канәгатьләндерү һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне үзгәртү турында

фикере һәм гомуми нәтиҗә теркәлә.

Беркетмә Комиссия рәисе, аның урынбасары һәм җаваплы сәркатибе тарафыннан имзалана.

Комиссия карары апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча соңгы булып санала, яңадан каралырга тиешле түгел һәм аңа карата суд тәртибендә шикаять бирелә ала.

## 5. Бәйге җиңүчеләре һәм дипломантлары

5.1. Бәйге җиңүчеләре һәм дипломантлары Комиссия утырышы вакытында билгеләнә. Комиссия билгеләрне Бәйгедә катнашучылар алдында дәлилләми.

5.2. Бәйгенең һәр номинациясендә һәр ике яшьтәге төркемнән өчәр җиңүче билгеләнә – 1, 2, 3 урыннар. Бәйгенең һәрбер номинаци җиңүчесе дә Дәүләт комитетының махсус дипломнары һәм истәлекле призлары белән бүләкләнә.

5.3. Бәйге җиңүчеләрен билгеләү катнашучыларның бәйге проектларының сыйфатын бәяләү критерийлары нигезендә 10-баллы шкала (әлеге Нигезләмәгә 3-нче номерлы Кушымта) буенча башкарыла.

5.4. Бәйге комиссиясе әгъзасы һәрбер критерий буенча ун баллы шкала буенча билге куя. Һәрбер критерий буенча җыелган билгеләр суммасы Бәйгедә катнашучының гомуми бәясен билгели.

5.5. Гаризага теркәлгән материалларны эшкәртү һәм анализлау, аларның объективлыгын бәяләү барышында Комиссия әгъзалары үзара ышаныч, шәхси җаваплылык һәм таләпчәнлек принципларыннан чыгып ун баллы шкала (1 балл – минималь билге, 10 балл – максималь билге) (әлеге Нигезләмәгә 6-нчы номерлы Кушымта) буенча бәя бирә.

5.6. Бәйгенең нәтиҗәләре турындагы карар Бәйге комиссиясе тарафыннан гомуми баллар санына карап һәм әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктыннан чыгып кабули ителә.

5.7. Бәйге комисииясе үзе артыннан Бәйгегә аның таләпләренә тулы дәрәҗәдә җавап бирүче бәйге проектлары тәкъдим ителмәгән очракта бер яки берничә призлы урынны бирмәү хокукын калдыра.

5.8. Бәйгене оештыручы белән алдан килешү буенча катнашучыларга үткәрелә торган Бәйге кысаларында аерым казанышлар өчен кызыксынган оешмалар тарафыннан өстәмә призлар һәм бүләкләр тапшырыла.

5.9. Бәйге комиссиясе карары нигезендә өстәмә номинацияләр буенча бүләкләү башкарыла.

5.10. Бәйге нәтиҗәләре Комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә төзелгән Дәүләт комитеты боерыгы белән аның имзалану көненнән башлап 3 эш көне аралыгында раслана.

5.11. Бәйге нәтиҗәләре 2019 елның 30 декабреннән дә соң түгел Дәүләт комитеты тарафыннан (аерым сценарий нигезендә) оештырылучы Бәйге җиңүчеләре һәм дипломантларын бүләкләү тантанасында игълан ителә.

Бәйге нәтиҗәләре турындагы игълан Бәйге җиңүчеләре һәм дипломантларын бүләкләү тантанасы үткәрелә торган көнне Дәүләт комитеты сайтында бастырыла.

5.12. Бәйгене оетыручылар үзләре артыннан:

тәкъдим ителгән бәйге материалларын үзәк, электрон массакүләм мәгълъмат чараларында бастыру;

материалларны челтәрле теле- һәм радиокомпанияләр эфирында урнаштыру;

бәйге җиңүчеләренең бәйге проектларын катнашучының авторлыгына сылтама белән Дәүләт комитетының сайтында урнаштыру хокукларны калдыра:

5.13. Катнашучылар әлеге нигезләмәнең барлык шартлары белән дә тулы һәм берсүзсез килешүне Бәйгегә үзләренең бәйге документларын җибәрү факты белән раслый.

5.14. Катнашучылар аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыкларын Бәйгегә үзләренең бәйге документларын җибәрү факты белән раслый.

2019 елда IX «Тамырларыбызга
сәяхәт» республикакүләм
бәйгесен үткәрү турында
Нигезләмәгә 1-нче номерлы
Кушымта

**2019 ел IX «Тамырларыбызга сәяхәт» республикакүләм бәйгесендә катнашучының**
**СОРАУНАМӘ-ГАРИЗАСЫ**

**Номинация: «Туристлык төрләре буенча иң яхшы маршрут»**
**Бүлек** (кирәкле урыннарны билгеләргә)
- тарихи мирас маршруты
- авыл туристлыгы маршруты
- этнотуристлык маршруты
- актив туристлык һәм ял итү маршруты
- сәнәгать туристлыгы маршруты
- гастрономия туристлыгы маршруты.

1. **Тутыру датасы «_____» «_____________» 2019 ел.**

2. **Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тутырып)**
________________________________________________
________________________________________________

3. **Яше** ________________________________

4. **Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме**
________________________________________________
________________________________________________

5. **Катнашучының тору җире адресы/ уку йорты урнашкан адрес:**
________________________________________________
________________________________________________

6. **Элемтә өчен телефоннар, электрон почта** (e-mail)___________________________
________________________________________________

7. **Катнашучы турында мәгълүмат:**
- уку йортының/эш урынының исеме һ.б. (тутырып)
________________________________________________
________________________________________________
- башка өстәмә мәгълүматлар _____________________________________________
________________________________________________
________________________________________________

8. **Тәкъдим ителгән эшнең исеме, кыска аннотация**
________________________________________________
________________________________________________

9. **Бәйге комиссиясе чыгарган нәтиҗәләр**

2019 елда IX «Тамырларыбызга сәяхәт» республикакүләм бәйгесен үткәрү турында Нигезләмәгә 2-нче номерлы Кушымта

**2019 ел IX «Тамырларыбызга сәяхәт» республикакүләм бәйгесендә катнашучының СОРАУНАМӘ-ГАРИЗАСЫ**

**Номинация** (кирәкле урыннырны билгеләргә)
- o Иң яхшы видео-экскурсия
- o Вакыйгалы туристлык өлкәсендә иң яхшы проект

| |
|---|
| **1. Тутыру датасы «_____» «_____________» 2019 ел.**<br><br>2. **Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (тутырып)**<br>________________________________________<br>________________________________________<br><br>3. **Яше** ______________________________<br><br>**4. Җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме**<br>________________________________________<br>________________________________________<br><br>**5. Катнашучының тору җире адресы/ уку йорты урнашкан адрес:**<br>________________________________________<br>________________________________________<br><br>**6. Элемтә өчен телефоннар, электрон почта** (e-mail)__________________________<br>________________________________________<br><br>**7. Катнашучы турында мәгълүмат:**<br>- уку йортынын/эш урынының исеме һ.б. (тутырып)<br>________________________________________<br>________________________________________<br>- башка өстәмә мәгълүматлар ___________________________________<br>________________________________________<br>________________________________________<br><br>**8. Тәкъдим ителгән эшнең исеме, кыска аннотация**<br>________________________________________<br>________________________________________ |
| **9. Бәйге комиссиясе чыгарган нәтиҗәләр** |

2019 елда IX «Тамырларыбызга сәяхәт» республикакүләм бәйгесен үткәрү турында Нигезләмәгә 3-нче номерлы Кушымта

**Катнашучыларның материаллары сыйфатын бәяләү критерийлары**

| Критерий исеме | Баллар | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** |
| Игълан ителгән номинацигә туры килү | | | | | | | | | | |
| Эчтәлекнең иҗадилык һәм мавыктыру дәрәҗәсе | | | | | | | | | | |
| Материалның хикәяләү стиле, теле (аныклык, кыскалык, лексика, грамматика) | | | | | | | | | | |
| Туристлык төшенчәләрен һәм терминнарны куллана белү | | | | | | | | | | |
| Тәкъдим ителгән материалның тикшеренү тирәнлеге | | | | | | | | | | |
| Бәйге проектын Бәйге турындагы Нигезләмә таләпләренә җавап бирерлек төзү | | | | | | | | | | |
| * «Экскурсия җитәкчесе портфеле» булуы | | | | | | | | | | |
| * Экскурсия контроль тексты булуы | | | | | | | | | | |
| * Маршрут карта-сызымы булуы | | | | | | | | | | |
| **Җентекле икътисади нигезләү | | | | | | | | | | |
| *** Техник яктан эшләнеше (видеога төшерү сыйфаты, видеоролик монтажы, башкару катлаулыгы) | | | | | | | | | | |

* «Туристлык төрләре буенча иң яхшы экскурсия маршруты»

** «Вакыйгалы туристлык өлкәсендә иң яхшы проект» номинацисе өчен бәяләнә

*** «Иң яхшы видео-экскурсия» номинацисе өчен бәяләнә